# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Олы Яке торак пунктында

30 нчы октябрь 2023 ел №9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Олы Яке торак пунктында гражданнар җыены

**Карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Яке авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, студентлардан, 1 нче группа инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- зиратларны төзекләндерү (Олы Яке авылы, Кече Яке авылы, Грыжбай авылы);
- территорияне төзекләндерү (контейнер мәйданчыгы төзү);

күпернең перильле коймасын буяу, балалар мәйданчыгына һәм Мәктәп урамындагы 3 нче йорт тирәсендә койма сатып алу һәм урнаштыру;

- юл үткәргечне ремонтлау.

3. Әлеге карарны Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Фәйзуллина